**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 23 июнь № 455

г. Казань

Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең бүтән субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән югары технологик медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килгән чыгымнарны финанслашу максатында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2015 елда Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән югары технологик медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килгән чыгымнарны финанслашу максатында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү турында» 2014 ел, 27 декабрь, 1572 нче карары үтәү өчен һәм сәламәтлек саклау тармагында чараларны тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлә торган Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең бүтән субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән югары технологик медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килгән чыгымнарны финанслашу максатында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе гражданнарына югары технологик медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килгән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатында

Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану турында» 2012 ел, 20 октябрь, 888 нче карарын көчен югалткан дип таныырга.

3. Бу карарның көче 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\455.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 23 июнь, 455 нче
карары белән расланды

**Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең бүтән субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән югары технологик медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килгән чыгымнарны финанслашу максатында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану**
**ТӘРТИБЕ**

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән Россия Федерациясенең бүтән субъектлары территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән югары технологик медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килгән чыгымнарны финанслашу максатында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану механизмын билгели.

2. Федераль бюджеттан субсидияләр Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган бердәм счетка киләләр.

3. Бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчаны тотуны Казначылыкта ачылган шәхси счет аша Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

4. Бу Тәртиптә күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына бирү бюджет ассигнованиеләре күләме һәм бюджет йөкләмләре лимитлары кысаларында федераль бюджеттан акча кергәннән соң Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Казначлыктан субсидияләр килү турында мәгълүмат алынганнан соң Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын финанслауга чыгым тәртибен Казначылыкка тапшыра.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Казначылыкның акча килү турында мәгълүматы нигезендә югары технологик медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт йөкләмәсен финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләрне медицина оешмаларының Казначылыкта ачылган, бюджет һәм автоном учреждениеләр акчасы белән операцияләрне исәпкә алу өчен билгеләнгән шәхси счетларына күчерә (алга таба – субсидия алучылар).

7. Субсидияләр федераль бюджет акчасы исәбеннән югары технологик медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт йөкләмәсен финанслар белән тәэмин итүгә

субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән субсидияләр алучылар арасында төзелгән килешүләр нигезендә бирелә.

8. Мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән югары технологик медицина ярдәме күрсәтүгә максатчан акча медицина оешмалары тарафыннан югары технологик медицина ярдәме күрсәтүдә катнашучы медицина хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүгә, югары технологик медицина ярдәме күрсәтү өчен дарулар һәм чыгым материаллары сатып алуга, медицина оешмасын карап тотуга чыгымнарга юнәлдерелә.

9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәге шартлар булганда бирелгән субсидияләрне өлешчә яки тулысынча кире кайтаруны тәэмин итә:

күрсәтелгән акчага ихтыяҗның булмавы (кимүе);

автоном һәм бюджет сәламәтлек саклау учреждениеләренең дөрес бумаган хисап тапшыруы;

автоном һәм бюджет сәламәтлек саклау учреждениеләренең акчаны максатчан файдаланмавы.

10. Субсидия алучыларның бу Тәртиптә билгеләнгән шартларны бозуы фактлары билгеле булган очракта, бирелгән субсидияләр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбен алган мизгелдән соң 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучылар субсидияләрне кире кайтару вакытын бозганда, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыт тәмамланган мизгелдән соң 30 көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә субсидияләрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча чаралар күрә.

11. Субсидияләрне алучылар:

федераль бюджеттан субсидия финанс чыганагы булып торган югары технологик медицина ярдәме күрсәтү буенча чыгымнарның, шулай ук югары технологик медицина ярдәме күрсәтелгән пациентларның аерымланган исәбен алып баралар;

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5 көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртип һәм формалар нигезендә югары технологик медицина ярдәме күрсәтү турында хисап һәм финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы субсидияләр булган чыгымнар турында хисап тапшыралар.

12. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән тәртипкә һәм формаларга ярашлы рәвештә медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән югары технологик медицина ярдәмен күрсәткәндә барлыкка килгән чыгымнарны финанслашу максатларында 2015 елда Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү турында килешү белән

билгеләнгәннәргә ирешү хакында хисап, медицина оешмалары тарафыннан субсидияне файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәсе һәм финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы федераль бюджеттан субсидияләр булган Татарстан Республикасы бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

13. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнә.

14. Медицина оешмалары тарафыннан субсидияләрне максатчан файдалануны контрольдә тотуны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

15. Бу карар нигезендә бирелгән акчаны максатчан файдаланмау Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

F:\KARAR\2015\455.docx